**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ**

**Борискинскогосельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы**

**Борис авыл Җирлеге**

**СОВЕТЫ**

Адрес: 422883, РТ, с. Борискино, ул. Дружбы, 8
тел: : 8 (84346) 76-239

Адресы: 422883, РТ, Борис авылы, Дуслык ур., 8
факс: 8 (84346) 76-239

**РЕШЕНИЕ** **Борис ав.** **КАРАР**

2025 елның " 25 " июне № 106

Әлки муниципаль районы Борис авыл җирлеге Советының 23.10.2023 елның №69 «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Борис авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында карар проекты

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» (соңгы үзгәрешләре белән), 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», Борис авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында " карар проектын 1 нче кушымта нигезендә беренче укылышта хупларга.

2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашуы турында" проект буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен (2 нче кушымта);

3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе (3 нче кушымта).

«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын 2025 елның 25 июлендә 10.00 сәгатьтә авыл җирлеге Советы бинасында гавами тыңлаулар уздырырга.

4. Махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (1 нче кушымта) урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

5.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

- Мәхмүтов Фәргать Фоат улын - Борис авыл җирлеге Советы депутатын;
- Гатауллин Илшат Габделхак улын - Борис авыл җирлеге Советы депутатын;
- Зварич Григорий Сергеевичны - Борис авыл җирлеге Советы депутатын.

6. Эшче төркемгә «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге депутатлар Советы депутатларының һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге депутатлар Советы каравына чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

ТР Әлки муниципаль районы
Борис авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Г.В.Самарина